# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Касай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**от 30.11.2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Касай торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 30 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Касай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

- Скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, Касай авылында су үткәрү челтәрен төзекләндерү

- Касай авылын кардан чистарту (хезмәт шартнәмәсе буенча тракторчыга түләү)

- Касай авылы зиратын карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу һәм коймаларны яңарту)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 61 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 32 кеше, бу 52,4 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 32 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Касай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Касай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчалары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, Касай авылында су үткәрү челтәрен төзекләндерү

- Касай авылын кардан чистарту, (хезмәт шартнәмәсе буенча тракторчы өчен түләү)

- Касай авылы зиратын карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу һәм коймаларны яңарту)

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
авыл җирлеге Башлыгы Х.Л.ЗАКИРОВ

Совет Кадыбашского сельского поселения
Кадыбаш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002572